**СОВЕТ
ЧЕРЕМУХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423195, РТ, Новошешминский район,
село Слобода Черемуховая, улица
Пролетарская, 47

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧЕРЕМУХОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

423195, РТ, Яңа Чишмә районы,
Черемухово Бистәсе авылы,
Пролетар урамы, 47

тел.:(884348)35-4-17, факс: (8-84348)35-4-17, Cher.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Черемухово авыл җирлеге советы утырышы
КАРАРЫ

2020 елның 16 декабре №5-16

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата түләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында " 2018 елның 1 октябре 42-94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге Советы карарын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге Советы
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата түләүләр, Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 1 октябре 42-94 номерлы карарына (алга таба – Карар)1 пунктның 16 пунктчасындагы «дәүләт» сүзен төшереп калдырып, түбәндәге үзгәрешләр кертергә (14.12.2018 №44-105, 15.06.2020 №64-152, от 13.11.2020 №4-12)карарлар редакциясендә).

2. "Яңа Чишмә муниципаль районының Черемухово авыл җирлеге даими нигездә муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү тәртибе" (алга таба – Тәртип) карарына 15 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.1. 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле икенче һәм өченче абзацлар белән тулыландырырга:

«Муниципаль хезмәткәргә, яисә даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта гына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирелә.

Әлеге бурычны түләү, бер тапкыр бирелә торган бүләкләүне алу өчен мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынганда, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла.».

2.2. Кушымтаның атамасындагы "дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.3. Тәртипнең 1 пунктындагы "дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.4. Тәртипнең 2 пунктындагы 1 абзацындагы" "дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.5. Тәртипнең 2 пунктындагы 3 абзацындагы "дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.6. Тәртипнең 3 пунктындагы «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.7. Тәртипнең 7 пунктындагы «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2.8. Тәртипнең 12 пунктындагы " дәүләт» сүзен төшереп калдырырга.

2.9. Тәртипнең 10 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Тәртипнең 5, 6 пунктларында каралган барлык документлар да тапшырылмаган очракта, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Черемухово авыл җирлеге Финанс-бюджет палатасы бер тапкыр бирелә торган акчаны түләүдән баш тарта.»;

2.10. "Муниципаль вазыйфаи зат" сүзләрен "муниципаль вазыйфаны биләүче зат" сүзләренә алмаштырырга (тиешле килештә);

2.11. 3,4 пунктларда «һәм» сүзен "яки" сүзенә алыштырырга;

2.12. 5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"муниципаль хезмәттә яки муниципаль вазыйфаны биләү вакытындагы эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте раслаган белешмә»;

2.13. 6 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"кадрлар хезмәте тарафыннан расланган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү вакыты турында белешмә»

3. Әлеге карарны "Интернет"мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда (http:/ / pravo. tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Черемухово авыл җирлеге Башлыгы — Е.А. Сальцина